РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ИЗМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422052, Республика Татарстан, Сабинский район, с.Измя, ул. Школьная, 9
тел. (84362) 49-1-32, (84362) 49-1-22

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЭЗМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422052, Татарстан Республикасы, Саба районы, Эзмә авылы, Мәктәп урамы, 9 йорт
тел. (84362) 49-1-32, (84362) 49-1-22

e-mail: Izm.sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ 01.07.2021

КАРАР №54

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан расланган 15.06.2021 елгы № 50 Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлеге муниципаль торак фондының социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондыннан торак урыннарны яллаучылар өчен торак урыннардан (наемга түләү) файдаланган өчен түләүне исәплəү тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Торак кодексы, Россия Төзелеш Министрлыгының 19.06.2017 елгы 892/пр номерлы боерыгы нигезендә, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык Министрлыгының 2016 елның 27 сентябрендәге 668/пр номеры белән расланган «Социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучылар өчен түләү күләмен билгеләүнең методик күрсәтмәләренә үзгәрешләр кертү турында» боерыгына таянып, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлеге муниципаль торак фондының социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондыннан торак урыннары наемга алу шартнамәләре буенча торак урыннары наемга алучылар өчен торак урыннардан файдалану (наемга түләү өчен) күләмен исәпләү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында, Эзмә авыл җирлеге Башкарма комитетының 15.06.2021 елгы 50 номеры белән расланган “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлеге муниципаль торак фондының социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондыннан

торак урыннары наемга алу шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучылар өчен торак урыннарыннан (наемга өчен) файдаланган өчен түләү күләмен исәпләү тәртибе турындагы Нигезләмә” карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Яллаучылар өчен түләү коэффициенты торак урыныннан файдаланган өчен түләү (наем өчен түләү) билгеләнгән вакытка – 0,3 күләмендә билгеләнә.

Шул ук вакытта гражданнарның түбәндәге категорияләре өчен түләүнең ташламалы критерийлары билгеләнә:

- 3 һәм аннан да күбрәк баладан торган күп балалы гаиләләр өчен-0,15;

- пенсионерлар өчен (55 яшькә җиткән хатын-кызлар һәм 60 яшькә җиткән ир-атлар) -0,15;

- инвалидлар өчен – 0,15.».

2.Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлегенең рәсми сайтында: http://saby.tatarstan.ru/rus/izma адресы буенча һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Эзмә авыл
җирлеге башлыгы А.Р.Шәйхетдинов